*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2025-2026 нчы уку елы)
**10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 44**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) утырдык
   ә) шунда
   б) шикелле
   **в) ашаганчы**

2. ***Кагыйдә*** сүзенең беренче авазына туры килә торган характеристиканы билгеләгез. **(2 балл)**
   **а) шаулы, саңгырау, яңгырау пары [ғ], кече тел, авыз тартыгы**
   ә) шаулы, яңгырау, саңгырау пары [г], тел арты, борын тартыгы
   б) шаулы, саңгырау, яңгырау пары [ғ], тел арты, авыз тартыгы
   в) шаулы, саңгырау, яңгырау пары [г], кече тел, борын тартыгы

3. Бирелгән фразеологик әйтелмәнең мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
   ***Җилләр исү***
   а) авырый башлау
   ә) күп эш башкару
   **б) берәр әйбернең кинәт юкка чыгуы**
   в) гел ялган сөйләү

4. Сүз ясагыч кушымчаны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) -ның/-нең
   ә) -рак/-рәк
   б) -са/-сә
   **в) -сыз/-сез**

5. Җөмләдәге тартым белән төрләнгән исемнәрнең санын билгеләгез. **(2 балл)**
   *Филнең – теше, боланның башы кыйммәт.* (Мәкаль)
   **а) 2**
   ә) 3
   б) 4

в) 1

6. Җөмләдәге затланышлы фигыльләрнең санын билгеләгез. **(2 балл)**

*Балачактан өйрәнмәсәң, картайгач үкенерсең.* (Мәкаль)

а) 1

**ә) 2**

б) 3

в) 4

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**

*Зур фил дә **тычканнан** курка.* (Мәкаль)

а) ия

ә) урын хәле

б) аергыч

**в) тәмамлык**

8. Җөмләдәге иярчен компонентның мәгънә ягыннан төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Фил күтәрмәгәнне тел күтәрә.* (Мәкаль)

а) иярчен ия җөмлә

ә) иярчен хәбәр җөмлә

**б) иярчен тәмамлык җөмлә**

в) иярчен аергыч җөмлә

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган авазны һәм сүзләрне языгыз. **(6 балл)**

**Интонация** – сөйләмнең ритмик-мелодик ягы. [**й**] – тел уртасы тартыгы. Сузык авазга беткән иҗек **ачык** иҗек дип атала. Һәрвакыт үзара антоним булган сүзләр **даими** антонимнар була. **Саналмышы** төшеп калса, сан исемләшә һәм сан, тартым, килеш белән төрләнә башлый. Җөмләнең мәгънәсе аңлашылсын өчен кирәк булган җөмлә кисәкләре барысы да кулланылса, ул **тулы** җөмлә була.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Сүзләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**

| | |
|---|---|
| *дыхание – сулыш* | *полынь – әрем* |
| *гостинец – күчтәнәч* | *берег – яр* |
| *пыль – тузан* | *лебедь – аккош* |

2. “Туган тел (татар теле) дәресендә” дигән темага 12 җөмләдән торган инша языгыз. **(16 балл)**